ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Азнакай муниципаль районы составына керүче «Азнакай шәһәре», «Әгерҗе авыл җирлеге» һәм «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.


**2 статья**

«Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (IV өлеш); 2008, № 8 (III өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2014, № 12 (X өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

«Азнакай муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге составына керүче
муниципаль берәмлекләрнең чикләре
**карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның
чиктәш чикләре тасвирламасы

12 (21) - 54 (22) - Башкортостан Республикасы
54 (22) - 34 (74) - Ютазы муниципаль районы
34 (74) - 26 (73) - Бөгелмә муниципаль районы
26 (73) - 7а (72) - Әлмәт муниципаль районы
7а (72) - 2 (71) - Сарман муниципаль районы
2 (71) - 12 (21) - Мөслим муниципаль районы

«Азнакай муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге составына керүче
шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Азнакай шәһәре |
| 2 | Актүбә шәһәр тибындагы поселогы |
| 3 | Әгерҗе авыл җирлеге |
| 4 | Әлкәй авыл җирлеге |
| 5 | Әсәй авыл җирлеге |
| 6 | Балтач авыл җирлеге |
| 7 | Бирючевка авыл җирлеге |
| 8 | Вахитов авыл җирлеге |
| 9 | Югары Стәрле авыл җирлеге |
| 10 | Илбәк авыл җирлеге |
| 11 | Кәкре Елга авыл җирлеге |
| 12 | Карамалы авыл җирлеге |
| 13 | Мәлбагыш авыл җирлеге |
| 14 | Мәсгут авыл җирлеге |
| 15 | Микулино авыл җирлеге |
| 16 | Сәпәй авыл җирлеге |
| 17 | Сарлы авыл җирлеге |
| 18 | Сукаеш авыл җирлеге |
| 19 | Татар Шуганы авыл җирлеге |
| 20 | Туйкә авыл җирлеге |
| 21 | Тымытык авыл җирлеге |
| 22 | Уразай авыл җирлеге |
| 23 | Урманай авыл җирлеге |
| 24 | Урсай авыл җирлеге |
| 25 | Үчәлле авыл җирлеге |
| 26 | Чалпы авыл җирлеге |
| 27 | Чемодурово авыл җирлеге |
| 28 | Чубар Абдул авыл җирлеге |

»;

2) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Азнакай муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы
турында» Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

**Азнакай муниципаль районының**
**«Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең**
**картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

«Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Әгерҗе, Сәпәй һәм Уразай авыл җирлекләре белән чиктәш.

«Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Әгерҗе авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге, Әгерҗе һәм Уразай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Туйкә авылыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 32а тоташу ноктасыннан алып, Стәрле елгасын кисеп үтеп, 350 м төньяк-көнбатышка таба Азнакай – Ютазы – М-5 автомобиль юлы буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнбатышка таба, 1,4 км төньяк-көнбатышка таба бара, алга таба 600 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м көньяк-көнбатышка таба, 500 м көньякка таба, 450 м көнбатышка таба бара, аннары 650 м төньякка таба Бөгелмә – Азнакай автомобиль юлы буйлап уза, алга таба төньяк-көнбатышка, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, Азнакай шәһәрен әйләнеп үтүче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,4 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м, көньяк-көнбатышка таба 250 м, төньяк-көнбатышка таба 400 м һәм, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 1,5 км, юл буе урман полосасын кисеп үтеп, Әлмәт – Азнакай автомобиль юлына кадәр бара, көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, әлеге автомобиль юлы буйлап 800 м, Әлмәт – Азнакай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның авыл хуҗалыгы җирләре буйлап әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чигенә кадәр 100 м, сазлыкның төньяк-көнбатыш чиге буенча 100 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көньяк-көнбатышка таба, 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 2,4 км

көньяк-көнбатышка таба урман полосасын кисеп үтеп бара, алга таба әлеге урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 200 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 700 м, төньяк-көнбатышка таба 1,3 км «Әлмәт – Азнакай» – Әгерҗе автомобиль юлына кадәр бара, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 400 м һәм төньякка таба 850 м Әлмәт – Азнакай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чигенә кадәр бара, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 2,0 км уза, аннары көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, «Азнакай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Азнакай участок урманчылыгындагы 118 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м бара, алга таба көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м, «Азнакай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Азнакай участок урманчылыгындагы 117 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км уза, аннары 550 м төньяк-көнбатышка таба күмәк бакчаларның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба көнчыгышка Әлмәт – Азнакай автомобиль юлы буйлап 4,1 км һәм әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап 1,7 км уза, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Әлмәт – Азнакай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм Рус Акташы – Азнакай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, аның төньяк-көнчыгыш чигенә кадәр 200 м бара, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м инешкә кадәр уза, инеш агымы буенча 550 м аска таба бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 300 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м көнчыгышка таба, 150 м көньякка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 300 м көньяк-көнчыгышка таба, 100 м төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары көнчыгышка таба «Азнакай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Чатыртау участок урманчылыгындагы 85 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, Мәнәвез елгасын ике тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 200 м бара, алга таба 150 м көньяк-көнчыгышка таба буаның уң яры буенча уза, аннары 100 м көнчыгышка таба буа буенча бара, аны кисеп үтә, алга таба төньяк-көнчыгышка 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 85 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м һәм көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 100 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 150 м төньякка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба бара, 150 м төньяк-көнбатышка таба 85 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба 400 м төньяк-көнчыгышка таба 83 нче, 84 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге, Әгерҗе һәм Сәпәй

авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Мәнәвез авылыннан 1,0 км көнчыгышта урнашкан 45 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Сәпәй авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 45 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба «Азнакай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Чатыртау участок урманчылыгындагы 84 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 850 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 78 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба профильле автомобиль юлы буйлап Азнакай шәһәрен әйләнеп үтүче автомобиль юлына кадәр 500 м бара, әлеге автомобиль юлы буйлап төньяк-көнчыгышка таба 500 м уза, алга таба, сынык сызык ясап, 1,2 км көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Азнакай – Дүсем автомобиль юлына кадәр бара, әлеге автомобиль юлы буйлап 750 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары 750 м көньяк-көнбатышка таба профильле автомобиль юлы буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Азнакай – Тымытык – Күктәкә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба төньяк-көнчыгышка әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м һәм Азнакай – Тымытык – Күктәкә автомобиль юлы буйлап 600 м «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге, Сәпәй һәм Уразай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Уразай авылыннан 1,9 км көнбатышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Уразай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып 800 м көнчыгышка таба Азнакай – Югары Стәрле – Күктәкә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап уза, аннары көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 750 м, күмәк бакчаларның көнчыгыш чиге буйлап 300 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м көньяк-көнчыгышка таба, 550 м көньяк-көнбатышка таба Стәрле елгасына кадәр уза, әлеге елга агымы буенча 500 м өскә таба бара, алга таба көньяк-көнбатышка, инешләрне һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 950 м, урман массивы буйлап 100 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм канауны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, «Азнакай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Азнакай участок урманчылыгындагы 127 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, 127 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы Стәрле елгасын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 450 м бара, кибеп баручы Стәрле елгасын кисеп үтеп, 1,2 км сазлык буенча 32а тоташу ноктасына кадәр уза.»;

3) 5 нче кушымтада дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгерже авыл җирлеге чиге «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Әгерже авыл җирлеге, «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Уразай авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Туйкә авылыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 32а тоташу ноктасыннан алып, Стәрле елгасын кисеп үтеп, 350 м төньяк-көнбатышка таба Азнакай – Ютазы – М-5 автомобиль юлы буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнбатышка таба, 1,4 км төньяк-көнбатышка таба бара, алга таба 600 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м көньяк-көнбатышка таба, 500 м көньякка таба, 450 м көнбатышка таба бара, аннары 650 м төньякка таба Бөгелмә – Азнакай автомобиль юлы буйлап уза, алга таба төньяк-көнбатышка, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, Азнакай шәһәрен әйләнеп үтүче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,4 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м, көньяк-көнбатышка таба 250 м, төньяк-көнбатышка таба 400 м һәм, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 1,5 км, юл буе урман полосасын кисеп үтеп, Әлмәт – Азнакай автомобиль юлына кадәр бара, көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, әлеге автомобиль юлы буйлап 800 м, Әлмәт – Азнакай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның авыл хуҗалыгы җирләре буйлап әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чигенә кадәр 100 м, сазлыкның төньяк-көнбатыш чиге буенча 100 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көньяк-көнбатышка таба, 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 2,4 км көньяк-көнбатышка таба урман полосасын кисеп үтеп бара, алга таба әлеге урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 200 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 700 м, төньяк-көнбатышка таба 1,3 км «Әлмәт – Азнакай» – Әгерже автомобиль юлына кадәр бара, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 400 м һәм төньякка таба 850 м Әлмәт – Азнакай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чигенә кадәр бара, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 2,0 км уза, аннары көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, «Азнакай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Азнакай участок урманчылыгындагы 118 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м бара, алга таба көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м, «Азнакай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Азнакай участок урманчылыгындагы 117 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км уза, аннары 550 м төньяк-көнбатышка таба күмәк бакчаларның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба көнчыгышка Әлмәт – Азнакай автомобиль юлы буйлап 4,1 км

һәм әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап 1,7 км уза, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Әлмәт – Азнакай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм Рус Акташы – Азнакай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, аның төньяк-көнчыгыш чигенә кадәр 200 м бара, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м инешкә кадәр уза, инеш агымы буенча 550 м аска таба бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 300 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м көнчыгышка таба, 150 м көньякка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 300 м көньяк-көнчыгышка таба, 100 м төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары көнчыгышка таба «Азнакай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Чатыртау участок урманчылыгындагы 85 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, Мәнәвез елгасын ике тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 200 м бара, алга таба 150 м көньяк-көнчыгышка таба буаның уң яры буенча уза, аннары 100 м көнчыгышка таба буа буенча бара, аны кисеп үтә, алга таба төньяк-көнчыгышка 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 85 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м һәм көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 100 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 150 м төньякка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба бара, 150 м төньяк-көнбатышка таба 85 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба 400 м төньяк-көнчыгышка таба 83 нче, 84 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 45 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

4) 18 нче кушымтада:

а) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сәпәй авыл җирлеге чиге «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Сәпәй авыл җирлеге, «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Әгерҗе авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Мәнәвез авылыннан 1,0 км көнчыгышта урнашкан 45 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба «Азнакай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Чатыртау участок урманчылыгындагы 84 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 850 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 78 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба профильле автомобиль юлы буйлап Азнакай шәһәрен әйләнеп үтүче автомобиль юлына кадәр 500 м бара, әлеге автомобиль юлы буйлап төньяк-көнчыгышка таба 500 м уза, алга таба, сынык сызык ясап, 1,2 км көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Азнакай – Дүсем автомобиль юлына кадәр бара, әлеге автомобиль юлы буйлап 750 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары 750 м көньяк-көнбатышка таба профильле автомобиль юлы буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Азнакай – Тымытык – Куктәкә автомобиль юлына

бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба төньяк-көнчыгышка әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м һәм Азнакай – Тымытык – Куктәкә автомобиль юлы буйлап 600 м Сәпәй авыл җирлеге, «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Уразай авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Уразай авылыннан 1,9 км көнбатышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

б) тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сәпәй авыл җирлеге чиге Уразай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 43 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м, урман полосасы буйлап 450 м, урман массивы буйлап 200 м, урман полосасы буйлап 700 м, «Азнакай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Чатыртау участок урманчылыгындагы 120 нче урман кварталының аерым торучы кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,0 км Вәрҗәде елгасына кадәр уза, чокырны кисеп үтеп, аның агымы буенча 2,0 км өскә таба Мачаклы инеше тамагына кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 1,4 км өскә таба Азнакай – Тымытык – Куктәкә автомобиль юлына кадәр уза, аннары әлеге автомобиль юлы буйлап 1,6 км көньяк-көнбатышка таба 44 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

5) 24 нче кушымтада җиденче һәм сигезенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Уразай авыл җирлеге чиге «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Уразай авыл җирлеге, «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Сәпәй авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Уразай авылыннан 1,9 км көнбатышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасыннан алып 800 м көнчыгышка таба Азнакай – Югары Стәрле – Куктәкә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап уза, аннары көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 750 м, күмәк бакчаларның көнчыгыш чиге буйлап 300 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м көньяк-көнчыгышка таба, 550 м көньяк-көнбатышка таба Стәрле елгасына кадәр уза, әлеге елга агымы буенча 500 м өскә таба бара, алга таба көньяк-көнбатышка, инешләрне һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 950 м, урман массивы буйлап 100 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм канауны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, «Азнакай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Азнакай участок урманчылыгындагы 127 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, 127 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы Стәрле елгасын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 450 м бара,

кибеп баручы Стәрле елгасын кисеп үтеп, 1,2 км сазлык буенча 32а тоташу ноктасына кадәр уза.

Уразай авыл җирлеге чиге Сәпәй авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Уразай, Сәпәй һәм Үчәлле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тәкмәле авылыннан 1,9 км төньяк-көнбатышта урнашкан 43 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м, урман полосасы буйлап 450 м, урман массивы буйлап 200 м, урман полосасы буйлап 700 м, «Азнакай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Чатыртау участок урманчылыгындагы 120 нче урман кварталының аерым торучы кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,0 км Вәрҗәде елгасына кадәр уза, чокырны кисеп үтеп, аның агымы буенча 2,0 км өскә таба Мачаклы инеше тамагына кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 1,4 км өскә таба Азнакай – Тымытык – Күктәкә автомобиль юлына кадәр уза, аннары әлеге автомобиль юлы буйлап 1,6 км көньяк-көнбатышка таба 44 нче тоташу ноктасына кадәр бара.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 29 сентябре
№ 74-ТРЗ

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

Үзгәрешләрне исәпкә алып,
муниципаль берәмлекләр чикләренең
<u>КАРТА-СХЕМАСЫ</u>




Шартлы билгеләр

- муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б - Әгерҗе авыл җирлегенең һәм «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең уртак чиге
- Б-В - Уразай авыл җирлегенең һәм «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең уртак чиге
- торак пунктлар
- җирлекләрнең административ үзәкләре

I - Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге территориясе

II - Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге территориясе